**Татарстан Республикасы**

**Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№127** **14.01.2019 ел.**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен расларга (кушымта).
2. Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге Советының 21.01.2013 елның 21 гыйнварындагы 66 нчы номерлы «Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге территориясендә тышкы төзекләндерү, территорияләрнең санитар эчтәлеге, җыештыру һәм чисталык тәэмин итү кагыйдәләре» карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлеге мәгълүмат стендлары һәм Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет Рәисе,**
**Гулкин авыл җирлеге башлыгы** **С.Д.Инькова**